КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 февраль г.Казань № 149

2024 елда сатулар үткәрмичә сатыла торган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен бәя билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 – 2024 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында, шулай ук федераль милектәге җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча ташламалы аренда түләве билгеләү очраклары һәм мондый түләү күләме турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^4$ статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 – 2024 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында, шулай ук федераль милектәге җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча ташламалы аренда түләве билгеләү очраклары һәм мондый түләү күләме турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарының 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган очракларда, Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сатып алу-сату шартнамәсен төзегәндә җир кишәрлегенең бәясе гражданның яки юридик затның мондый җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгате кергән вакытта

гамәлдә булган җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте күләмендә билгеләнә дип билгеләргә.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин